КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге составына керүче Юлбат торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

13.11.2020 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советының 25.10.2019 елның 25 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып 2020 елның 13 ноябрендә узган гражданнар җыенында «2021нче елда Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге составына керүче Юлбат торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Юлбат авылының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау;
- Юлбат авылының чишмәсен һәм янәшәсендәге территорияне төзекләндерү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 337 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 179 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 179 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге составына керүче Юлбат торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.

2. «2021нче елда Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге составына керүче Юлбат торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" дигән мәсьәлә буенча карар кабул итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) Юлбат авылының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау;

2) Юлбат авылының чишмәсен һәм янәшәсендәге территорияне төзекләндерү, карарын кабул ителгән дип таныргa.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ulbat адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Юлбат авыл
җирлеге башлыгы Т.Р. Шәмсиев